ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 һәм 42 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 16 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяга түбәндәге эчтәлекле 7 өлеш өстәргә:

«7. Бик яхшы билгеләре генә булган белгеч яки магистр дипломына ия затларга шул диплом бирелгән көннән алып өч ел дәвамында муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфаларын биләү өчен муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек буенча эш стажына карата квалификация таләпләрендә кимендә ярты ел муниципаль хезмәт стажы яки кимендә бер ел белгечлек буенча эш стажы булу карала.»;

2) 42 статьяның 4 өлешендә «белеме булу» сүзләреннән соң «һәм муниципаль хезмәт стажы яки белгечлек буенча эш стажына карата квалификация таләпләрендә тиешенчә кимендә ике ел яисә кимендә өч ел булу» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 22 февраль
№ 7-ТРЗ